Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Данауровка авылы җирлегенең Галактионово авылы торак пунктында
гражданнар җыены

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлеге составына керүче Галактионово авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре хакында

КАРАР

2019 елның 26 ноябре № 2

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 25.1, 56 нчы маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасының 35 нче маддәсе нигезендә түбәндәге сорау буенча 2019 елның 26 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлегенең Галактионово авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм I төркем инвалидлардан тыш, 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- Галактионово авылындагы юлларны (вак таш җәю) ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 116 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 66 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» тавышы өчен халык җыенында катнашкан 56 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 10 кеше тавыш бирде.

Алда язылганнар нигезендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлегенең Галактионово авылы торак пунктында гражданнар җыенын булды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.

2. “Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлегенең Галактионово авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм I төркем инвалидлардан тыш, 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- Галактионово авылындагы юлларны (вак таш җәю) ремонтлау буенча карар кабул ителде дип санарга.

3. Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлегенең Галактионово авылы территориясендә Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлегенең Галактионово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм I төркем инвалидлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Галактионово авылындагы юлларны (вак таш җәю) ремонтлау.

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм игъланнар такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга кирәк.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Данауровка авыл җирлеге башлыгы В.К. Садретдинова